МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 март 2019ел № И 133

Законнардагы һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турында нигезнамәне раслау хакында

Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының эшен камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингы турында» 2012 елның 15 маендагы ПУ-331 санлы Указы һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Законнардагы һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 27 мартындагы
М 133 нче карарына
кушымта

Законнардагы һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турында нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Законнардагы һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы үзгәрешләргә мониторинг үткәрү (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) муниципаль актларны кабул итүне (чыгаруны), үзгәртүне яки үз көчен югалткан (гамәлдән чыгарылган) дип тануны тәэмин итү өчен мәгълүматларны җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлекне күздә тота.

2. Мониторинг, җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре белән үзара хезмәттәшлек итеп, җирле үзидарә органнарының җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органнары структур бүлекчәләренең җитәкчеләре барлыкка килә торган хокук куллану проблемалары буенча квартал саен мәгълүмат бирергә тиеш.

4. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып түбәндәгеләр тора :

1) федераль һәм республика законнарына туры китерү максатында муниципаль актларны кабул итү, үзгәртү яки үз көчләрен югалткан дип тану ихтыяҗын ачыклау;

2) муниципаль актлардагы коллизияләрне, каршылыкларны, кимчелекләрне, хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;

3) җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын системалаштыруны тәэмин итү;

4) муниципаль актларда коррупция факторларын ачыклау;

5) зарурлыгы булмаган (актуальлеген югалткан) яки практикада кулланылмый торган муниципаль актларны яки аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

6) хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген киметә торган факторларны ачыклау;

7) муниципаль актларның үтәлешенә җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан контрольне гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

8) нормалар билгеләү процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү .

5. Мониторинг түбәндәгеләрнең үзгәрешләрен җыюны, гомумиләштерүне, анализлауны һәм бәяләүне үз эченә ала:

1) федераль конституция законнары, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актлары;

2) Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге законга кагылышлы башка норматив хокукый актлар;

3) Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль актлар.

6. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелү;

2) хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

3) прокуратура органнары мәгълүматы;

4) муниципаль актлардагы җитешсезлекләр яки аларны камилләштерү кирәклеге турында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

5) гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында, шул исәптән түбәндәгеләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләре:

- Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертелгән муниципаль актларга карата Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

- аны үткәрүгә вәкаләтле затлар тарафыннан билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән муниципаль актларга карата коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган конференцияләрнең, семинарларның, җәмәгать тыңлауларының, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документлары.

## 2 бүлек. Мониторинг үткәрү тәртибе

7. Мониторинг үткәрү максатында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып

алынырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләренең, Россия Федерациясе субъектларының тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары файдаланылырга мөмкин.

8. Мониторинг түбәндәгеләрне анализлау аша гамәлгә ашырыла:

1) әлеге Нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелгән актларны;

2) федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актларын (суд практикасын);

3) прокурор эше актларын.

9. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән нормалар билгеләү эше нәтиҗәләрен теркәү максатында, шәһәр Хакиме Карары нигезендә алып барыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү өчен түбәндәгеләрне тәэмин итә торган мәгълүмат системаларының автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлек булганда):

1) «Гарант», «Консультант» мәгълүмат системасында контрольгә куелган закон һәм башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр турында мәгълүмат керү;

2) «Гарант», «Консультант» мәгълүмат системасын хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар хакында мәгълүмат керү;

3) «Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан муниципаль актларның законнарга туры килмәве ачыклану турында мәгълүмат керү.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

11. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (чыгаруны), үзгәртүне яки үз көчен югалткан (гамәлдән чыгарылган) дип тануны тәэмин итү өчен, әлеге Нигезнамәнең 8 пунктында күрсәтелгән анализ белән беррәттән, муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат түбәндәге критерийлар буенча гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

1) кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

2) муниципаль актларны кабул итү (чыгару) зарурлыгы билгеләнгән югарырак юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;

3) муниципаль актны чыгарганда, җирле үзидарә органы компетенциясе чикләрен саклау;

4) муниципаль актта коррупция факторлары булу;

5) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуның тулылыгы;

6) хокук нормаларында коллизия;

7) юридик-техник характердагы хаталар булу;

8) муниципаль актны кулланганда аның нигезләмәләренең мәгънәсе бозылу;

9) муниципаль хокукый актны кулланганда, хокуксыз яисә нигезсез карарлар, эш итүләр (эш итмәү);

10) норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

11) норматив хокукый актларны куллануда бер төрдәге практика булмау;

12) муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар булу (саны) һәм аларның эчтәлеге;

13) муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә гариза бирүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында закон көченә кергән суд актлары булу (саны) һәм аларны кабул итү нигезләре.

12. Муниципаль актларны үзгәртү зарурлыгына китергән федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, мониторинг федераль яки республика акты чыгарылган вакыттан башлап 30 көн эчендә үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнарның, юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, дәүләт хакимияте органнарының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутатларының мөрәҗәгатьләре, шулай ук прокуратура мәгълүматы торса, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законда билгеләнгән срокларда карап тикшерелә торган прокурор эше актларыннан тыш тыш, мониторинг алар кергән көннән башлап 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән очракларда мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать иткән затка хәбәр ителә.

13. Мониторинг нәтиҗәләре әлеге нигезнамәгә кушымтада каралган бәяләмә белән рәсмиләштерелә. Бәяләмә мониторинг үткәрүгә мөнәсәбәтле һәр муниципаль хокукый акт буенча төзелә.

14. Мониторинг нәтиҗәләре буенча, федераль һәм республика законнарында муниципаль актларны үзгәртүгә китерә торган үзгәрешләр ачыкланган очракта, тиешле муниципаль акт проектын әзерләү өчен, эшчәнлеге өлкәсендә хокук нормасы җайга салына торган җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләренә тиешле хат җибәрелә.

## 3 бүлек. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль актны кабул итү, федераль һәм (яки) республика законнарының тиешле акты үзгәргән вакыттан башлап ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Мониторинг нәтиҗәләре буенча кабат кабул ителгән муниципаль актлар, законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан

Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрелә.

Күрсәтелгән регистрга кертү өчен, анда булмаган, мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган муниципаль актлар җибәрелә.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча нормалар билгеләү процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары — Ф.И. Андреева

Шәһәр Хакименең 2019 елның 27 мартындагы М 133 нче карары белән расланган законнардагы һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларындагы үзгәрешләргә мониторинг үткәрү турында нигезнамәгә кушымта

Муниципаль хокукый актка мониторинг үткәрү нәтиҗәләре буенча
БӘЯЛӘМӘ

«___» _______________20___ел

Әлеге бәяләмә ___________________________________________________________
(муниципаль хокукый акт реквизитлары: хокукый акт төренең исеме; хокукый актны кабул иткән җирле үзидарә органының исеме; датасы; номеры; хокукый актның исеме)
муниципаль хокукый актка мониторинг үткәрү нәтиҗәләре буенча әзерләнде.
Муниципаль хокукый акт мониторингын башкаручы ____________________
(җирле үзидарә органы исеме)

Мониторинг ___________________________________________________________
(җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) Ф.И.А.и., вазыйфасы, телефоны)
тарафыннан үткәрелде.

Тапшырылган муниципаль хокукый актта түбәндәге каршылыклар һәм җитешсезлекләр ачыкланды (ачыкланмады) :
_____________________________________________________________________.
(каршылыклар һәм җитешсезлекләр ачыкланган очракта, аларны норматив хокукый актларга сылтамалар белән тасвирлау башкарыла)

Ачыкланган каршылыкларны, җитешсезлекләрне, коррупция факторларын ___________________________________________________ бетерү максатында
(кыскача тасвирлана каршылыклары, җитешсезлекләр)

тәкъдим ителә (киңәш ителә):
_____________________________________________________________________
(каршылыкларны, җитешсезлекләрне, коррупция факторларын бетерү мөмкинлеге турында тәкъдимнәр, киңәшләр күрсәтелә: муниципаль хокукый акт текстыннан норманы төшереп калдыру, аны башка редакциядә бәян итү, карап тикшерелә торган муниципаль хокукый акт текстына яисә башка муниципаль хокукый актка башка үзгәрешләр кертү, гамәлдән чыгару (үз көчен югалткан дип тану) яки башка ысул)

Кушымта: ____ биттә.

______________________________________________
(мониторингның җаваплы башкаручысы
вазыйфасының исеме (имза) (Ф. И.А.и.))